СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №127 (7456) | 24 октябрь, 1992 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

*25 октябрь—Автомобиль транспорты хезмәтчәннәре көне.*

*Бәйрәмегез белән сезне, кадерле иптәшләр!*

## Бәйрәмне вахтада

Халык хуҗалыгы йөкләрен ташуда автомобиль транспорты гаять зур роль уйный. Йөкләр күчерүнең, пассажирлар йөртүнең күпчелек өлеше алар җилкәсенә төшә.

Норлат-Октябрь автопредприятие коллективы үзенә йөкләтелгән шул бурычларны уңышлы гамәлгә ашыру өчен тырыша. Автомобиль йөртүчеләр үткән 9 айда йөкләр ташу заданиесен 102,9 процентка үтәп чыктылар. Юл йөрүче халыкның ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча да билгеле уңышларыбыз бар. Беренче өч квартал заданиесе 106,1 процент итеп үтәлде. Керем алу планын да үтәү тәэмин ителде.

Безнең предприятие район ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә хезмәт итә. Һәр көн иртән йөк автомобильләре предприятиеләр, оешмалар заказларын үтәү өчен рейска чыга. Юллары ерак шәһәрләргә, башка республика, өлкәләргә кадәр сузыла аларның.

Көзге-кышкы чорда алар күп очракта төзелеш материаллары, башка төр халык хуҗалыгы йөкләре ташыйлар. Җәйге чорда колхоз-совхозларда үстерелгән уңышны җыюда, кабул итү пунктларына илтүдә эшлиләр. Әйтергә кирәк, быел бу кампаниядә катнашучы шоферларыбызга эш җитәрлек булды, икмәк, шикәр чөгендере, терлек азыгы культуралары да уңышны мул бирде. Уңган шоферлар Илья Васьков, Алмаз Нәфыйгин, Андрей Семенов, Алексей Шпаров һәм башка күпләр авыл уңганнарына нәтиҗәле ярдәм күрсәттеләр. Алар бүген профессиональ бәйрәмебез алдыннан да киеренке хезмәт итәләр, янәшәдәге иптәшләренә маяк, үрнәк булып торалар.

Автобус йөртүчеләребез дә үз вазифаларына үтә җаваплы карыйлар, халыкны билгеләнгән урынга вакытында илтеп җиткерү өчен тырышалар. Бу хакта сөйләгәндә иң элек шәһәр халкын йөртүче Владимир Атяшевны билгеләп үтү урынлы. Хәер, башка маршрутларга йөрүчеләр арасында да уңган, намуслы шоферларыбыз аз түгел. Николай Никифоров, Харис Мөхәммәтов, Равил Әюпов һәм тагын күп автобусчыларыбызның фидакарьлеге нәтиҗәсендә бу тармак планнарын тотрыклы үтәп килә.

Бүген, һәр тармактагы кебек үк, автомобиль йөртүчеләр дә катлаулы шартларда эшли. Ягулыкка, запас частьләргә, машиналарга бәяләр көн саен диярлек үсә, билет бәяләре күтәрелә. Бу заказлар кимүгә, хезмәт күрсәтүнең бәясе үсүгә, ахыр чиктә предприятиенең финанс-экономик хәленә дә тискәре йогынты ясый.

Әмма коллектив бу кыенлыклардан чыгу, хәлне стабильләштерү, халык, хезмәт коллективлары ихтыяҗларын тулы канәгатьләндерү өчен тырышып хезмәт куя, бәйрәмне шулай киеренке хезмәттә каршы ала.

**В. КАДЫЙРОВ,**
Норлат-Октябрь предприятиесе экономисты.



Хәрби киемен җилкәсеннән салып, авыл мәшәкатьләре белән яши башлавына 2 еллап кына әле Валерийның. Совет Армиясе сафларыннан кайтып колхозда эшләргә теләк белдерүен ике куллап хуплап алдылар. Башта ул колхоз автобусында эшләде, быел инде үзенә куәтле КамАЗ машинасы бирделәр. Валерийның беләгендә көче, йөрәгендә яшьлек дәрте ташып торган чагы, инде кулында егәрле тыңлаучан машина да булганда, тау-таш актарырга мөмкин. Валерий шулай авылдашлары сокланырлык эшли дә. «Беренче май» колхозында азык әзерләүдә дә, ашлык ташуда да, чөгендерне заводка озатуда да Валерийның КамАЗы иң алдынгылар, иң җитезләр исәбендә булды, хуҗалыкның башка эшләрендә дә сынатмый.

РӘСЕМДӘ: «Беренче май» колхозы шоферы В. Васильев.

## *Шоферлар авылга булыша*

Автомобиль транспорты работниклары бәйрәмен билгеләп үткән бу көннәрдә дә безнең аерым шоферлар авылдан чимал—шикәр чөгендере ташу белән мәшгульләр әле. Моңа аерым басым ясауның сәбәбе бер—«Октябрьскремтехпред» шоферлары беренче чиратта игенчеләргә ярдәм итүне төп бурычлары итеп саныйлар. Урак чорында, мәсәлән, дистәләрчә автомобильләр ындырга ашлык, ферма яннарына яшел масса ташуда эшлиләр.

Хәзер дә авыл ихтыяҗлары—предприятие шоферларының беренчел заказы. Чит дәүләтләргә чыгып, меңнәрчә чакрым юл үтеп запас частьләр алып кайталар. Шулай булмыйча, предприятие мастерскоена колхоз-совхозлардан ремонтка техника керә, аларны төзекләндерү кирәк.



Хәер, колхозлар өчен терлекләр, төзелеш материаллары һәм башкаларны да ташыйлар автотранспортчылар. Замир Әхмәтов, Хәйдәрҗан Ногъманов, Владислав Авторов, Сергей Якунин, Иван Никитин, Николай Охотников һәм башка автомобиль йөртүчеләр бу эштә аеруча өлгерләр.

Күмәк тырышлык белән предприятие шоферлары йөк әйләнеше, тулай табыш алу һәм башка төр күрсәткечләр буенча да планнарын гамәлгә ашыралар.

**Р. ЗАҺРЕТДИНОВ.**

*Кискен сигнал*

## Мунча гына димәгез!...

«Шәһәр мунчасында юыну хакы 9 сум икән хәзер!—дип каршылады мине күршем эштән кайтканда.—Сменадан буш көнемдә кинәнеп бер юынып кайтыйм әле дигән идем, насыйп булмады. Кем генә йөрер икән ул мунчага хәзер?»

Йөрүчеләр булыр, әлбәттә. Тормыш үзе мәҗбүр итәр. Һәр гаилә үзенә аерым мунча булдыру бәхетенә ирешә алмый, ләбаса. Бәяне арттыручылар шуңа исәп тоткандыр да. Ләкин безнең шәһәр мунчасындагы шартлар бит әле аның моңача түләп килингән бәясен—2 тәңкәне дә акларлык түгел. Кайнар яки салкын суның үзгәреп торуын инде санга да алмыйбыз. Ә менә андагы җыйнаксызлыкның, тайгак идәннәрнең мунчага йөрүчеләрнең җанын биздереп торуы һәммәбезгә мәгълүм бит. 18 октябрь көнне кичке сәгать 6.00дан соң шәһәр мунчасына килүчеләр исә тагын бер «сюрприз»га юлыктылар: 3 чегән хатыны тирәюньдәге юынучы халыкка исе дә китмәстән, душ янында керләрен юдылар. Өстәвенә киенә торган якка ләгән белән су алып чыгып, аның эченә дә кереп бастылар (ә бит без ул ләгәннәрдә битебезне дә юабыз!) Шакшы киемнәренә кабат киенүче чегәннәрне, аларның кыланмышларын күргән шәһәр халкы мунчачыларга мөрәҗәгать иттеләр, әмма мунча мөдиренең әлеге чегәннәр янында бик күңелле гәп корып басып торуын күргәч, өмет өзеп китәргә ашыктылар. Инде менә яңа хәбәр. «Юыну хакының артуы дөресме?» дип мунчага шалтыраткан идем дә бик көр тавышлы бер ханым: «Әйе, 21 нче октябрьдән башлап 9 сум!»—дип күтәренке күңел белән җавап бирде... Шәһәр күләмендә уйлап карагыз әле: бәя артудан кем отар, бу «яңалык» нинди нәтиҗәләргә китерер икән? Өч тиенлек куян, 5 тиенлек зыян булмасмы бу?..

**К. ҖАМАЛЕТДИНОВА.**

## Планнар үтәлә

Норлат-Октябрь ит комбинаты коллективы быелның 9 аенда планнарын үтәү өстендә киеренке эшләде.

Түбәндәге саннардан күренгәнчә, коллектив барлык төр буенча да җитештерү планнарын арттырып үтәде. Мәсәлән, тулай продукция айлык планга карата, шул исәптән дәүләт чималыннан ит җитештерүне 105,6 процентка үтәде. Колбаса әйберләре 109,8 процент, терлек мае 110,3 процент, коры азык 111,4, ярымфабрикат әйберләре җитештерү планы 131,6 процентка үтәлде.

Коллектив җиткерелгән продукцияне реализацияләү өстендә дә әйбәт эшли. Биредә бер эшләүчегә җитештерүне арттыруга да игътибар бирелә. Участоклар һәм цехлар да әйбәт эшлиләр. Сую цехыннан Анна Ивановна Самохвалова, 20 елдан артык хезмәт куючы терлек суючы Леонид Алексеевич Сухарев, эчәк эшкәртү цехыннан Гөлсинә Җамалетдинова, терлек мае цехыннан Зәмзәмия Гобәйдуллина, тиреләрне тозлау цехыннан Валентина Филимонова, котельнядан Геннадий Данилович Филимонов тормыш иптәше Елена белән бергә, компрессор цехыннан Андрей Николаевич Васин һәм Вәлияр Галәветдинов, суыткычта эшләүче Галия Кәримовна Гатауллина, Алексей Майоров, Илгиз Мортазин, механика цехыннан Илсур Әнвәрович Кармышев һәм автотранспорт цехыннан Борис Синдряков—нәкъ шундый уңганнар.

Сую, терлек мае һәм техник фабрикатлар цехы мастеры Любовь Николаевна Чернованың планнар үтәлешенә аеруча зур өлеш кертүен әйтеп үтәсе килә. Любовь Чернова ит комбинатына эшкә килгәндә аңа бары 15 яшь кенә була. Үзенең хезмәт юлын ул колбаса цехыннан башлый. 1970 нче елда комбинат аны мастерлар хәзерләү мәктәбенә укырга җибәрә. Аннан кайткач шушы цехта эшен мастер булып дәвам иттерә һәм 23 ел вакыт узып та китә.

Хәзер ул комбинатның иң тәҗрибәле, уңган эшчеләреннән санала, һәм андыйлар биредә аз түгел. Шундый уңган, тырышлар белән коллектив хаклы рәвештә горурлана ала. Һич шик юк, ит комбинаты тулаем еллык планнарны үтәп чыгачак.

**Ю. НӘБИУЛЛИН.**

# ЖУКОВ БРИГАДАСЫННАН

—Исәнмесез!

Вахтада торучы—көне буе койган яңгырдан шактый юешләнергә, пычранырга өлгергән ир-ат безгә җавап урынына баш кына селкеде. Хәер, шуннан артыгы таләп тә ителми: көчле скважина тавышы астында барыбер ишетелмәячәк иде. Бораулаучы, инде бу тавыш, бу эшлекле атмосферага күнгән нефтьче, безнең сөйләшергә азаплануыбызны күреп көлемсерәде генә.

—Сергей Соколов ул. Әлегә аның вахтасы эшли, ә 16 сәгатьтә аларны Давыдов егетләре алыштырачак.

Боларны безгә үз вагончыгында мастер Владимир Александрович Жуков сөйли. Тәрәзәгә көзге яңгыр бәрә, әле генә скважина яныннан, тыштан кергән Владимир Александровичның чәч очларыннан аның соңгы бөртекләре тама.

—Күрдегезме, егетләрне? Менә шундый инде ул безнең нефтьче хезмәте: яңгырда да, әче салкында да вахта туктатылмый, кешеләр эшли.

Әйе, романтик бизәкләү сүзләре бүген телгә килми. Мамык авылы артында агачы-куагы да, аланлыгы да булган бу урын, бәлки, җәйге аяз җылы көнне җәлеп итәрлек почмактыр. Әмма хәзер, ачы яңгыр, актарылып ташланган җир, көчле җил, иртә иңеп барган караңгылык һәм коточкыч тавыш фонында нефтьчеләрнең авыр хезмәте бар тулылыгы белән күз алдына килә.

Владимир Алексеевич шул шартларда 19 ел эшли. Октябрьск шәһәренең нефть техникумын тәмамлады, дизельчы, аннан бораулаучы ярдәмчесе булып эшләде, инде менә соңгы 7 елын бораулау мастеры вазифасында. 32 кешене берләштергән бу коллектив эшчәнлеге өчен иң элек ул җавап бирә. Бригада график нигезендә эшли. Скважина тик торуга юл куелмый. Менә хәзер егетләр. Зүзәй нефть үткәрүчеләр заказын үтиләр, бу эксплуатация скважинасы, нефтьчеләр өчен аерым катлаулылык уята торган объект түгел. Биредә скважина төзү буенча тулы күләмдә эшне башкарырга кирәк булачак. Әлегә бригада эшен уңышлы алып бара. Хәер, коллектив НУРБда гомумән әйбәт эшләүче бригада санала. Алдагы скважинаны да ул нормада каралган 16 урынына 12 көндә тәмамлады, 9айлык планны да (дәрес, аңа ничәмә-ничә тапкыр төзәтмәләр кертелде) 108,9 процентка үтәде. Бу саннар артында никадәр киеренке хезмәт ятуын аңлау читен түгел. Хәзер скважина, җиһазлар иске, торбалар җитешмәгәнлектән өзеклекләр туып тора. Шуның өстенә, бораулау өчен җир алу мәсьәләсе дә елдан-ел катлаулана бара. Ә нефтьчеләрнең төп бурычы нәрсәдән гыйбарәт —иң элек скважинаны сыйфатлы төзеп, югалтуларсыз заказчыга тапшырудан. Шуның өстенә, аларга бораулау темпын тизләтү дә моңа кадәр төп бурычларның берсе иде. Әмма соңгы вакытта аны сан ягыннан арттыру өстәмә чыгымнар таләп иткәнлектән, идарә өчен файда китерүдән бигрәк мәшкатькә әйләнә бара. Шуңа да планнар кыскара, тизлекне арттыруның әһәмияте бетә.

Әмма эшне туктатырга да ярамый. Гомерләренең күп өлешен шул хезмәткә багышлаган нефтьчеләр тулы нагрузка белән омтылышлы эшләргә гадәтләнгәннәр. Жуков бригадасында да андый уңганнар байтак. Бораулаучылар Виктор Арсентьевич Давыдов, Исхак Рәхмәтуллин, Минһади Вәлиуллин, бораулаучы ярдәмчеләре Габбас Ильясович Хамматов, Фәрит Зәйнетдинов, Вәлиәхмәт Сафин, өлкән дизельчы Геннадий Баранков— коллективның шундый тәҗрибәле, уңган членнары, нефтьче дигән мактаулы исемне горурлык белән йөртүчеләр. Бригадада хезмәт дисциплинасы турында сүз гомумән кузгатылмый диярлек хәзер, егетләрнең һәммәсе бирелеп, бар күңелләрен куеп эшлиләр. Шуңа бригада турында НУРБда бер фикер күптән ныгыган инде:

—Жуковныкылармы? Алар бер дигән, эшчән егетләр. Чын нефтьчеләр!

**С. НУРУЛЛИНА.**

Җәй көннәрендә урып-җыю вакытында аларның һәр икесе комбайн штурвалы артына утыра, моннан тыш Равил Зәйдулович хуҗалык ихтыяҗы буенча кранчы хезмәтен дә башкара. Чөгендер сезонында Марат Хәйдәрҗанов исә чөгендер күтәртү комбайнында эшли.

Хәзер һәр икесе җәйге техниканы саклауга кую белән мәшгульләр. Аннан Марат үзенең МТЗ-80ендә күчеп эшли башлаячак. Р. Нәмаев исә кочегар хезмәтенә күчәчәк. Тырыш, эшчән кеше һәр хезмәтне җиренә җиткереп башкара торган була, Нәмаев белән Хәйдәрҗанов хезмәтеннән дә «Үрнәк» колхозында канәгатьләр.



РӘСЕМДӘ: «Үрнәк» колхозы механизаторлары Р. З. Нәмаев һәм М. Хәйдәрҗанов.

## • Сездә ничек? Бездә шулай.

Бәйрәмнәр күпме соң бездә? Юк шул, кызганычка каршы. Ә ул безгә су, һава кебек үк рухи азык буларак бик тә кирәк ләбаса. Сабыйларның сихри дөньясына чумып, бу катлаулы тормышның бар борчуларын, көндәлек мәшәкатьләрен аз гына онытып ял итәр өчен генә булса да бәйрәмнәр кирәк безгә. Ә бәйрәмдә исә балаларның ут кебек янып торган чая күзләрен, сөйкемле йөзләрен күрү, шат авазларын ишетү үзе иң-иң олы бәхетләрнең берседер, мөгаен. Чөнки алар белән бергә уйныйсың, көләсең, җырлыйсың, биисең, хәтта алар белән бергә ярышасың. Шулай итеп, бәйрәм көннең килеп җитүен дә балалар сабырсызлыгы белән дулкынланып, түземсезлек белән көтәсең.

# Их күңелле бәйрәме!..

16 НЧЫ ОКТЯБРЬ көнне Югары Норлат урта мәктәбендә уңыш бәйрәме була икән дигән хәбәр дә авыл өстенә яшен тизлеге белән таралды. Шулай итеп балаларның шатлык-куанычлары әти-әниләренә, әби-бабайларына да күчте, бергәләп хәзерлек эшләрен башладылар.

Традиция буенча мәктәп залында укучылар үзләре үстергән яшелчәләрдән, яшь экологларның фенсологик күзәтү дәфтәрләреннән, табигый материаллардан ясалган экспонатлардан күргәзмә оештырдылар. VI класс укучыларының көче белән чыгарылган бик эчтәлекле «Уңыш-92» стена газетасы да, фотовитрина да бәйрәм атмосферасы тудырды.

Менә зарыгып көтеп алган көн дә килеп җитте. Дәртле музыка яңгырады. Әлбәттә, җыр укытучысы Сәлим Шакирович Фәхретдинов кайчан нинди көй уйналырга тиешлеген яхшы белә. Бәйрәмчә бизәлгән залга ап-ак сакаллы, мәһабәт гәүдәле, гәрәбә төсендәге сары атлас күлмәктән «Уңыш-бабай» килеп керде. «Оныклары» аны саклык белән генә кәнәфигә утыртып сәхнәгә күтәреп менделәр. Ипи-тоз, бодай көлтәләре күтәргән, татар милли киемнәре кигән кызлар да залның түреннән урын алдылар. «Уңыш бабай» ролен башкаручы хуҗалыкның төрле тармакларында эшләп чыккан, VIII класс укучысы Рәүф Сабиров мөгезле эре терлекләр симертү буенча хуҗалыкара берләшмәнең алтын куллы уңганнарына «чал чәчле» башын иеп олы рәхмәтен белдерде, ирешелгән уңышлар белән таныштырды. Ашлык ташуда Минәхмәт Алиев, Наил Фәтхетдинов һәм Фәнис Бикбаев абыйларына тиңнәр табылмаган икән. Шикәр чөгендерен ташучылар арасында да Зәйдулла Әхмәтсафин, Равил Мортазин, Шәйхулла Мөхәммәтов иң җитезләрдән булганнар. Ә менә татлы тамыр игү буенча звено җитәкчеләре турында шигъри юллар да иҗат иткәннәр:

Алдынгылар алдынгысы
Мөхәммәтов Зәйдулла
Чөгендер игү буенча
Чын оста диеп була.
Яруллин Шамил абыйның
Куллары алтын икән,
Фидакарь хезмәте аны
Орденлы, данлы иткән.

Әти-әниләренең, туганнарының хезмәттәге уңышлары укучыларда, әлбәттә, горурлык хисе уятмый калмагандыр. Әнә берничәсе хәтта, мине күрәләрме икән дигәндәй, эчкерсез елмаеп, шатлыгын яшерә алмыйча як-ягына каранып куйды.

Чайкала иген кырлары,
Уяна таң нурлары...

Х класс укучысы Рамил Хаҗиморатовның гармунын сыздырып уйнап, классташлары белән шулай үзәкләрне өзәрлек итеп җырлый-җырлый залга килеп керүе бәйрәмне тагын да җанландырып җибәрде. Рамил оста җырчы, тирә-юньдә танылган гармунчы гына түгел, ул быел алдынгы комбайнчы исеменә дә лаек булды. Егетнең булдыклылыгына, тырышлыгына авылда сокланмаган кеше юктыр. Көнне төнгә ялгап туган кырларында ашлык суктыруда куйган хезмәтенең нәтиҗәсе дә куанычлы, әнә бит уч тутырып алырлык хезмәт хакы да шуны раслый, 10 мең сум өз акча түгел инде. Шуңа да «Уңыш бабай» указы буенча Рамилгә «алтын медаль» тапшырылды. Җәйге хезмәт чирегендә иң актив катнашучы укучылар «көмеш медаль» белән бүләкләнделәр. Менә ул хезмәт сөюче уңганнар: VI класс укучысы Илнур Мусин, VII нче класстан Фәрит Билданов, VIII нче класстан Илназ Шәфиев, Роберт Әхмәтсафин, Рәүф Сабиров, IX нчы класстан Марсель Мусин, Илназ Галиев, Нәфис Кәбиров, X нчы класстан Фаил Кәбиров, XI нче класстан Илнар Мөхәммәтҗанов, Зилия Әхсәнова, Айгөл Мөхәммәтова. «Уңыш бабай» аларны чын күңелдән кайнар котлады, уңышлар теләде.

Бәйрәмдә дару үләннәреннән ромашкалар һәм мәтрүшкәләргә, икенче икмәк—бәрәңгегә дә дан җырланды, хөрмәтләп искә алынды. Ә VIII—IX класс укучылары турында үзләре җырлаган җырларының сүзләре белән: «Матурлар, алтын кебекләр, эштә ялкын кебекләр»,—диясе килә. 1 һәм V класс укучыларының да иҗади отчетлары бик ошады. Төрле-төрле бүлмә гөлләре үстерүләре турында матур итеп җырлап күрсәтүләре һәркемнең күңеленә хуш килде. Башлангыч класслар укытучысы Нурания Шәрифулла кызы Галәветдинованың укучылары һәр бәйрәмгә яңа җыр бүләк итәләр. Бу юлы да ирексездән аларга кушылып җырлыйсы килде, күңел үзен бу минутларда куе урманның чәчәкле аланында итеп хис итте. Ә менә II класс кызларының күбәләк кебек очып-очып биюләре берәүне дә битараф калдырмады, болай булгач киләчәктә авылыбызның менә дигән хореографлары да була икән әле дигән өмет чаткылары уятты. Өлкән класс укучыларының рекламалары, «Мексика артистлары»ның чыгышлары да алкышларга күмелде. Гомумән, сокланып, рәхәтләнеп карарлык концерт номерлары күп булды.



Ә бәйрәм һәр класста алдан ук әзерләнгән, сый-нигъмәттән сыгылып торган, тәмле-татлы ризыклар белән тулы, матур итеп бизәлгән табын янында дәвам итте. Соңыннан оештырылган җыр-биюләр, викторина һәм төрле уеннардан берәү дә читтә калмады. Һәркемнең йөзендә—зур канәгатьлек билгесе. Эх, күңелле дә соң тирләп-пешеп, янып-көеп эшләгәннән соң уйнап-көлеп бәйрәм итүләре.

**Г. МӨХӘММӘТОВА,**
Югары Норлат урта мәктәбенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары.

# Ишеттегезме әле...

✦Каян килде безгә хәерчеләр? Мөгаен, капиталистик илләрдәндер. Ник дигәндә, «аларда» хезмәт ияләренең коточкыч шартларда яшәве турында телевизион тапшырулар күренми башлады, газеталарда да бу хакта мәкаләләр юк. Димәк, хәерчеләр хәзер Көнбатыштан безгә күчеп килгәннәр.

Кайбер белгечләр раславынча, Русия халкының өчтән ике өлеше хәерчелек сызыгының теге ягында яши. Ә бу 100 миллион кеше дигән сүз.

## САУЛЫКХАНӘ

### *Бүген бездә кунакта—белгеч табиб*



# Калкансыман биз турында нәрсә белергә



Калкансыман биз—бик мөһим орган, организм өчен кирәкле йодлы гормоннар чыганагы. Бу гормоннар организмның сәламәт булуы өчен күпме кирәксә—шул күләмдә һәм шул тизлектә эшләнәләр. Нормадан аз гына тайпылыш та авыру китереп чыгара.

Калкансыман бизнең нормаль эшләве өчен йод кирәк. Ул бизнең гормоннар эшләп чыгаруында катнаша. Азыкта йод җитмәгәндә, шулай ук ул организмга күпләп кергәндә, калкансыман бизнең эшчәнлеге бозыла. Бу очракта ул гормоннарны йә җитәрлек күләмдә эшләп чыгармый (аның нәтиҗәсендә гипотиреоз дигән авыру башланырга мөмкин), яки кирәгеннән күп эшли (бусы—тиреотоксикоз дигән авыруга китерә). Бизнең үз тукымалары үзгәрсә дә (гормоннар җитештерү бозылмый) авыру башлана.

Калкансыман бизнең теләсә нинди зураюы зоб дип атала. Ул йод җитмәгәндә бизнең компенсатор зураюы, продукция күплегеннән, шулай ук биздә ялкынсыну яки шешү процесслары нәтиҗәсе булырга мөмкин.

Азыкларында йод җитешми торган кайбер районнарда яшәүчеләр эндемик зобтан интегәләр. Зоб зур булганда зурайган калкансыман бизнең сулыш юлына һәм үңәчкә басым ясавы нәтиҗәсендә буылу, коры ютәл приступлары, йотканда кыенлык булырга мөмкин. Әгәр зоб тын юлларына, үңәчкә, зур тамырларга һәм нервларга механик басым ясый икән, авыруны оператив дәвалауга җибәрәләр. Мондый районнарда профилактика максатларында тозны йод белән баеталар, антиструмин бирәләр.

Гипотиреоз булганда бизнең эшчәнлеге кими. Бу авыру хатын-кызларда күбрәк очрый. Авыруларны сүлпәнлек, йокымсырау, төшенкелек, әкренлек баса, өшү сизелә, тавыш карлыга, эч ката. Авыру көчле булганда тышкы кыяфәттә дә үзгәрешләр барлыкка килә: йөз шешенә, саргылт-ак төскә керә, күз уемнары тарая, телдә теш эзләре кала. Чәчләр сынучан, коры, бик тә күп коелалар. Тире калына, бармак белән басып караганда чокыраймый. Сөйләм әкренәя, аңлаешсыз була. Күп кенә авыруларның пульсы сирәгәя, салкын тиюләргә тизрәк бирешә башлыйлар. Еш кына азканлылык күзәтелә, хатын-кызларның менструаль циклы бозыла.

Гипотериоздан дәвалану өчен калкансыман биз гормоннарыннан эшләнгән дарулар кулланалар. Күп кешеләргә аларны озак еллар буена кулланырга туры килә. Дәвалануны туктатсаң, авыруның бөтен билгеләре яңадан кабатлана. Тиешле даруны бары тик табиб кына тәкъдим итә ала.

Авыруларның табибка үз вакытында мөрәҗәгать итмәве, яки таныш-белешләр киңәше белән генә дарулар кабул итүе авыр хәлләргә китерергә мөмкин. Бу вакытта инде табиб та ярдәм итәргә авырсынырга мөмкин.

Әгәр калкансыман биз гормоннарны ихтыяҗга караганда артык эшләп чыгара башласа, организмда токсик зоб үсеш ала. Бу очракта, кагыйдә буларак, калкансыман биз үсә, зурая башлый һәм аның төене дә үсә. Мондый авыру гадәттә шәһәр халкының 20 яшьтән 50 яшькәчә булганнары (бигрәк тә хатын-кызлар) арасында очрый.

Диффузияле токсик зоб исә инфекцион авыру (грипп, ангина, кискен һәм хроник тонзиллит) кичергәннән соң башланып китүчән. Бу авыруның нәселдән килгән очраклары да мәгълүм. Токсик зобның үсеп китүенә психик травмалар, гаиләдәге һәм эштәге конфликтлар, организмның кирәгеннән артык кызуы (кояшта озак булу) да сәбәп булырга мөмкин.

Йодның зур дозаларын кабул иткәндә дә калкансыман бизнең эшчәнлеге көчәю һәм токсик зоб үсеш алуы мөмкин. Шуңа күрә составында йод булган препаратларны (мәсәлән, атеросклероз яки башка авыруларны дәвалаганда) бары тик табиб күрсәтмәсе буенча һәм катгый билгеләнгән дозаларда гына кулланырга кирәк.

Калкансыман биз эшләп чыгарган гормоннарның ихтыяҗдан күплеге нәтиҗәсендә чамадан тыш нерв ярсучанлыгы, елаучанлык, ыгы-зыгылык, тиз аручанлык, йокы режимы бозылу барлыкка килә. Авырулар тирә-юньдәге кешеләр белән юктан да ачуланышып китәләр, килешмәүчәнгә әйләнәләр, курку хисе кичерәләр, игътибар туплау сәләтен югалталар, көчле тирләү, алга сузылган кулларның, кайвакыт бөтен тәннең калтыравы күзәтелә.

Авыруның иң характерлы, шунда ук читтәгеләргә күренә торган билгесе—акай күзлелек.

Авыруларны барыннан да элек йөрәк кагуы борчый. Бу халәт тыныч булганда да, йоклаганда да үзгәрми. Бу вакытта пульс ешлыгы минутына 120—140 тибештән гыйбарәт. Еш кына кан басымы күтәрелә, йөрәк тирәсендә стенокардияне хәтерләткән авырулар күзәтелә.

Калкансыман бизнең эшчәнлеге үзгәрүнең беренче билгеләрен сизүгә үк табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Авыруның табибка тулысынча ышануы, аның белән тыгыз элемтәсе дәвалануның мәҗбүри шарты. Авыруның төгәллеге, табиб кушканнарны җиренә җиткереп үтәү—уңышлы дәвалануның нигезе.

Хәзерге вакытта токсик зобка каршы көрәштә дарулар да, хирурглар да ярдәм итә. Дәвалау ысулын табиб-белгеч һәр кеше өчен махсус билгели. Монда бизнең зарарлану дәрәҗәсе дә, авыруның яше һәм гомуми сәламәтлеге дә исәпкә алына.

Һәр авыру күп аксымлы һәм витаминлы азык белән тукланырга тиеш. Куе чәй, кофе яратучыларга вакытлыча бу эчемлекләрне кулланмаска кирәк. Иң яхшысы—сөтле чәй, компотлар, кисельләр, соклар тәкъдим ителә.

Исерткеч эчемлекләр һәм тарту катгый тыела. Кояшта һәм бөркү биналарда булмау хәерле. Тәүлегенә 8 сәгатьтән дә ким йокламау, һәр көнне һавада йөрү киңәш ителә. Авырулар бәхәс-низаглардан читтәрәк булырга тырышсыннар. Авыруның билгеләре нык сизелгән кешеләргә санаторий-курортларда дәвалану (бигрәк тә эссе чорда) тыела. Кызганычка каршы, диңгездә коенырга яратучылар еш кына үз белдекләре белән көньякта ялга китәргә яраталар һәм моның белән сәламәтлекләренә зур зыян китерәләр. Авыру җиңелчә генә булганда җирле клиник зонада, урта полосада ял итәргә мөмкин.

Ялкынсынганда калкансыман биздә көчле авырту һәм киеренкелек сизелә. Башны борганда бу авырту көчәя. Югары температура, өшү, баш авыртуы, көчле тирләү була. Биз үзе зурая, авырта.

Сирәгрәк очракларда авыру астыртын башлана. Гомуми хәлсезлек, нык ару күзәтелә. Биз нык зурайган очракта йоту кыенлаша. Ялкынсынуны дәвалау озакка сузыла, табибтан да, авырудан да зур түземлек сорала. Дәвалау үз вакытында башланса, тулысынча терелеп җитү дә ышанычлы.

**С. ПЕРМЯКОВ,**
врач-эндокринолог.

---

✦Галимнәр иркәләү, назлау, үбү кеше организмында окситоцин гормоны бүленеп чыгуны көчәйтә, ә бу гормон кешедә бәхет хисе уята һәм стрессларга каршы тору сәләтен арттыра диләр. Ә кемгә мәхәббәт әләкми, аның башы авыртучан була, кан әйләнеше бозыла, ашказаны чәнчи.

## *АТ ДӘВАЛЫЙ*



ФИНЛЯНДИЯ больницаларының берсендә нерв бозылуы кичергән балаларны реабилитацияләүнең гадәти булмаган формасын практикага кертә башладылар. Балаларны дәвалауда врачларга атлар булыша.

Кагыйдә буларак, бу сеанста дүрт кеше катнаша—яшь пациент, психолог, инструктор һәм махсус өйрәтелгән ат. Белгечләр исәпләвенчә, бу ягымлы, эш сөючән һәм буйсынучан хайваннар кешеләрнең кәефен бик тиз сиземләп алалар һәм үзләрен тиешенчә тоталар икән. Алар кешеләрне сүздән түгел, ә үз-үзен тотуыннан, кешенең характерыннан ук аңлыйлар. Ә бала, үз нәүбәтендә, хайванның аның хәленә һәм тәртибенә карата битараф булмавын күреп, игътибарын ат белән мөгамәләгә юнәлтә һәм шулай итеп үзенең авыртуларыннан онытылып тора.

ТАСС фотохроникасы.

---




Фомада яшәүче әниебез Гәүһәрия Галимехәммәт кызына 56, әтиебез Сәлим Минәхмәт улы Гатинга 60 яшь тула. Аларны туган көннәре белән чын күңелдән котлап, һәр икесенә сәламәтлек, озын гомер, озак еллар бергә тигез яшәүләрен телибез.

**Улы, килене, кызлары, кияүләре, оныклары.**

---

### ТАБЫЛДЫКЛАР ӨСТӘЛЕНӘ

Самара өлкәсе Чаллы Башы районы Иске Ильдяково авылы янындагы Пролетарий поселогы көтүендә коба тана йөри. Ул 4 айга якын инде көтүдән Александр Песчанов хуҗалыгына кайта. Югалтучының аны эзләп хуҗага түгел, көтүгә баруы хәерлерәк. Чөнки хуҗаның югалтучыга башка малны күрсәтүе ихтимал. Авыл көтүенә килеп ияләшкән тананың коерыгы кисеп алынган булган, хәзер ул үскән. Шушы тамга буенча масын югалтучыны.

**Поселок халкы.**

---

## БЕЛДЕРҮЛӘР


Хосусыйлаштыру чеклары алырга хокукы булган гражданнар исемлеген төзү срогы бетеп килә.

Шәһәрдә шәхси йортларда яшәүче һәм кабат теркәү узмаган кешеләрнең теркәлү өчен документлар белән шәһәр Советы башкарма комитетына килүләре сорала.

**Шәһәр Советы башкарма комитеты.**

⊙ ⊙ ⊙

Октябрь райпосының «Коопродторг»ы сыер, дуңгыз, сарык итенең килограммын 90 сумнан кабул итә. Ит тапшыручылар белән исәп-хисап урында ясала.

⊙ ⊙ ⊙

«ТНГФ» производство берләшмәсенең күчмә механикалаштырылган колоннасын «ТНГФ»ның Норлат геофизик эшләр идарәсе белән бергә кушу сәбәпле үзара исәп-хисап эшләре «ТНГФ» производство берләшмәсенең Норлат геофизик эшләр идарәсе расчет счеты буенча 1992 елның 1 октябреннән башкарылачак.



**МӨХӘРРИР В. В. ИСХАКОВ.**

**Учредительләр: редакциянең хезмәт коллективы һәм халык депутатларының Октябрь район Советы.**

**Редакциянең адресы: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19. Телефоннар: мөхәррир 2—12—1[illegible] 2—22—81; мөхәррир урынбасары һәм советлар тормышы бүлеге 2—10—44; рус теленә тәрҗемә итү буенча мөхәррир урынбасары 2—14—16; чуваш теленә тәрҗемә итү буенча мөхәррир урынбасары 2—15—63; ав[illegible] хуҗалыгы бүлеге 2—10—44; яңалыклар һәм промышленность бүлеге 2—22—51; җаваплы секретарь, хатлар, массал[illegible] белән эшләү, радиотапшырулар бүлеге, бухгалтерия һәм реклама бүлеге 2— 18—67; фотокорреспондент 2—15—6[illegible]**

**Газетаның басылу сыйфаты турында типография директорына түбәндәге телефон белән мөрәҗәгать итәргә: 2-10-54.**

**Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор—Зөлфия ВӘЛИЕВА.**

**Күләме—1 басма табак**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Татарстан Республикасы информация һәм матбугат Министрлыгының Норлат-Октябрь типографиясе. Тираж 3751. Заказ 127.**